**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**Татарстан Республикасы**
**Яңа Чишмә муниципаль район Советы**
**КАРАРЫ**

**“13” нче декабрь 2018 нче ел** **№ 43-251**

**“2018 нче елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә ветераннарның, өлкәннәр яшьтәге гражданнарның социаль-икътисадый хәлен яхшырту, аларның сәламәтлеген ныгыту һәм актив озын гомерлелеккә ярдәм итү буенча мәгълүмат”**

Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Семеняк В. Н.ның 2018 нче елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә ветераннарның, өлкән яшьтәге гражданнарның социаль-икътисадый хәлен яхшырту, аларның сәламәтлеген ныгыту һәм актив озын гомерлелеккә ярдәм итү буенча мәгълүматын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2018 нче елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә ветераннарның, өлкән яшьтәге гражданнарның социаль-икътисадый хәлен яхшырту, аларның сәламәтлеген ныгыту һәм актив озын гомерлелеккә ярдәм итү буенча мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына:

2.1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлегенә мәктәп укучыларын һәм имин булмаган гаиләләрдәге балаларны патриотик тәрбияләүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрүне оештырырга.

2.2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлегенә түбән бәяләр буенча азык-төлек һәм азык-төлек булмаган товарлар сату буенча авыл хуҗалыгы ярминкәләрен оештырырга.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Яңа Чишмә муниципаль районындагы социаль яклау бүлегенә, Яңа Чишмә муниципаль районындагы «Забота " халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәгенә:

3.1. кирәкле ярдәм күрсәтү максатыннан өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның, шулай ук социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ затларның яшәү шартларын тикшерүне оештырырга.

3.2. Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә «Өлкән кешене кабул итүче гаилә» пилот проектын тормышка ашыруны, «Өлкән кешене кабул итүче гаилә» технологиясен алмаштыручы стационар кертүне тәэмин итәргә.

4. Яңа Чишмә ҮРХ уңайлылыкларны булдырырга, өлкән буын кешеләрен карау, үз-үзеңә хезмәт күрсәтү мөмкинлекләрен тормышка ашыруны тәэмин итәргә, бүлекчәләрне кирәкле җиһазлар һәм карау предметлары белән җиһазландырырга.

5. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлегенә өлкән сыйныф укучылары өчен Батырлык дәресләре уздырырга, Бөек Ватан сугышы һәм хезмәт ветераннары белән очрашу оештырырга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://novosheshminsk.tatarstan.ru/.бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә)

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Яңа Чишмә муниципаль районы Советының Социаль сәясәт буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы** **Козлов В.М.**